ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.04.2026 п.г.т.Алексеевское № 135

**Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 02.12.2020 ел, № 462 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын (юл хуҗалыгы объектларын) карап тоту регламентын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 08 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатында, «Автомобиль юлларының иминлеге» Таможня берлегенең (ТБ ТР 014/2011) Техник регламенты нигезендә

**карар бирәм:**

1. «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын (юл хуҗалыгы объектларын) карап тоту регламентын раслау турында Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 02 декабрендәге 462 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарга кушымтаның 2.1. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. автомобиль юлы - транспорт чаралары хәрәкәте өчен билгеләнгән һәм автомобиль юлының бүленгән полосасы чикләрендәге җир кишәрлекләрен һәм аларда яисә алар астында урнашкан конструктив элементларны (юл катламы, юл өслеге һәм шуңа охшаш элементларны) һәм аның технологик өлеше булып торучы юл корылмаларын, - яклау юл корылмаларын, ясалма юл корылмаларын, җитештерү объектларын, автомобиль юлларын төзекләндерү элементларын үз эченә ала торган транспорт инфраструктурасы объекты.»;

1.2. Карарга кушымтаның 2.18. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.18. «Тротуар » - җәяүлеләр хәрәкәте өчен билгеләнгән һәм машина йөрү өлешенә яки велосипед юлына тоташкан яки алардан газон белән аерылган юл

элементы.»;

1.3. Карарга кушымтаның 2.19 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.19. автомобиль юлларын тәшкил итү элементлары - юл билгеләре, юл киртәләре, светофорлар, юл хәрәкәтен җайга салу җайланмалары, автоматик режимда эшләүче стационар махсус техник чаралар, юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуларны теркәү өчен фотога һәм киного төшерү, видеога яздыру функцияләре булган, максималь массасы 12 тоннадан артык булган транспорт чаралары тарафыннан гомуми файдаланудагы федераль әһәмияттәге автомобиль юлларына китерелә торган зыянны каплау исәбенә түләү кертүне тикшереп торучы фото - һәм кино төшерү, видеога яздыру функцияләренә ия автомат режимда эшләүче стационар махсус техник чаралар, ял итү урыннары, тукталыш пунктлары, автомобиль юлларын яктырту өчен билгеләнгән объектлар, җәяүлеләр юллары, авырлык һәм габарит контроле пунктлары транспорт чаралары, түләү алу пунктлары, транспорт чараларын кую урыннары (парковкалары), автомобиль юлларын һәм ясалма юл корылмаларын саклау өчен билгеләнгән корылмалар, тротуарлар, юл хәрәкәтен, шул исәптән аның иминлеген тәэмин итү өчен каралган башка корылмалар, юл сервисы объектларыннан тыш.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://alekseevskiy.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Е.Н. Мельниковка йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**Җитәкчесе** **О.Н. Леденцов**